| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«01» июня 2021 с. Тюлячи № 200

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 23 сентябрендәге 453 номерлы «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының 2021 елның 17 мартындагы 20-08/3184 номерлы хатын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 5 октябрендәге 999 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 23 сентябрендәге 453 номерлы «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» карарына (24.02.2014 № 86, 23.05.2016 № 504, 23.03.2017 № 141, 12.09.2017 № 701, 12.09.2019 № 511, 10.04.2020 № 173, 29.01.2021 № 32 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү Тәртибенә:

- 2.1 пунктның «б» пунктчасын түбәндәге тәртиптә бәян итәргә:

«б) мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының бала өчен айлык пособие билгеләү турында гариза бирелгән ай алдыннан алты календарь айга кадәрге соңгы 12 календарь айның керемнәрен раслый торган документлар;».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә һәм 2021 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары – территориаль үсеш бүлеге башлыгы И.Ә. Миңнегуловка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин